**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУРКАЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОРКАЧЫК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык тимер юл разъезды бистәсе, Гагарин ур., 7

тел./факс 8(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 27 октябрь 2020** **№ 21**

## Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең бухгалтерлар хезмәте өчен түләүне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 05 августындагы 655 нче номерлы «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» карары нигезендә, Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Коркачык авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 28 ноябрендәге 57 нче номерлы «Баш бухгалтерлар һәм бухгалтерларның, Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендә аерым оешмалар хезмәткәрләренең, Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Башкарма комитетының хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләре хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» карары белән расланган «Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең бухгалтерлар хезмәте өчен түләүне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) оештыру һәм шартлары турында» Нигезләмәнең 3 пунктына «Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең бухгалтерларның вазыйфаи окладлары» таблицасына, (30.09.2020 № 17 Карары редакциясендә) түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары халык саны белән |
|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш бухгалтер | 16171 |

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында:

http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Коркачык авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Салихҗанов